**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**
IV чакырылыш IX утырышы

2022 елның 15 феврале №15 Урыссу ш.т.п.

"Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы,Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә:

- адресация объектларына адреслар бирү, адреслар үзгәртү, гамәлдән чыгару буенча, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципалитетара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге юлларыннан тыш) исемнәр бирү, җирлек чикләрендә планлаштырылган структура элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару, мәгълүматны дәүләт адреслы реестрында урнаштыру буенча;

- муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең Башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәләре нигезендә, «Татарстан Республикасы

Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына әлеге карарның 1 пункты нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны башкарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында “Рәсми Татарстан” дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә : http://jutaza.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
муниципаль районы Башлыгы -
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин.

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советының
2022 елның 15 февралендәге № 15
карарына

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы составына керүче җирлекләр
исемлеге

1. Урыссу шәһәр тибындагы поселогы;
2. Әбсәләм авыл җирлеге;
3. Акбаш авыл җирлеге;
4. Бәйрәкәтамак авыл җирлеге;
5. Бәйрәкә авыл җирлеге
6. Димтамак авыл җирлеге
7. Кәрәкәшле авыл җирлеге;
8. Иске Каразирек авыл җирлеге;
9. Ташкичү авыл җирлеге;
10. Урыссу авыл җирлеге;
11. Ютазы авыл җирлеге.

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советының
2022 елның 15 февралендәге
№ 15 карарына

№_____ КИЛЕШҮ
________________________________ Башкарма комитеты һәм
Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында.

Урыссу ш. т.п. "____"__________20__ ел

Алга таба Устав нигезендә эш итүче «Җирлек башкарма комитеты» дип аталачак ________________ Башкарма комитеты, бер яктан, "район Башкарма комитеты» дип аталачак Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе ____________________ исеменнән, Нигезләмә нигезендә, икенче яктан, икесе бергә “Яклар” дип аталачак, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Муниципаль берәмлек уставы һәм “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 28.04.2020 ел, № 1 карары белән әлеге Килешүне түбәндәгеләр турында төзеделәр:

## 1. КИЛЕШҮ ПРЕДМЕТЫ

1.1. Әлеге Килешүнең предметы булып җирлек Башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләрнең бер өлешен район Башкарма комитетына тапшыру тора:

- адресация объектларына адреслар бирү, адреслар үзгәртү, гамәлдән чыгару буенча, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципалитетара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге юлларыннан тыш) исемнәр бирү, җирлек чикләрендә планлаштырылган структура элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару, мәгълүматны дәүләт адреслы реестрында урнаштыру буенча;
- муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документларны рәсмиләштерү буенча.

## 2. ЯКЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Яклар бурычлы:

2.1.1. Әлеге Килешүнең 1.1 пунктында каралган вәкаләтләрне ________________ муниципаль берәмлеге һәм «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге гамәлдәге законнар таләпләре һәм мәнфәгатьләре нигезендә гамәлгә ашырырга;

2.1.2 әлеге Килешүнең 1.1 пунктында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны бирергә һәм тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруда методик ярдәм күрсәтергә;

2.2. Яклар хокуклы:

2.2.1 тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле карарларны мөстәкыйль кабул итәргә;

2.2.2 әлеге Килешүнең 1.1 пунктында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

2.2.3 тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр кертергә;

2.2.4 Дәүләт хакимиятенең кызыксынучы органнары һәм башка кызыксынган затлар белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашырырга, шул исәптән әлеге Килешүнең 1.1 пунктында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында Килешү төзергә;

Әлеге Килешү буенча тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән гамәлдәге законнарга каршы килмәгән теләсә нинди башка гамәлләрне гамәлгә ашырырга.

## 3. ВӘКАЛӘТЛӘРНЕ ҮТӘҮНЕ КОНТРОЛЬДӘ ТОТУ

3.1. Җирлек Башкарма комитеты тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, район Башкарма комитетыннан җирлек башкарма комитетының дәлилләнгән таләбе буенча тапшырылган финанс чараларыннан файдалану турында кирәкле мәгълүмат соратып ала.

3.2. Район Башкарма комитетына ел саен 31 декабрьгә кадәр вәкаләтләрнең үтәлеше, вәкаләтләрне үтәү өчен тапшырылган финанс чараларыннан файдалану турында хисап, шулай ук әлеге Килешү предметына кагылышлы аерым сорау буенча башка мәгълүмат җибәрә.

## 4. КИЛЕШҮНЕҢ ГАМӘЛДӘ БУЛУ СРОГЫ

4.1. Әлеге Килешү басылып чыккан көннән башлап үз көченә керә һәм 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

4.2. Якларның берсе дә, әлеге Килешүнең гамәлдә булу вакыты тәмамланырга бер ай кала, башка Якка Килешүне өзү хакында нияте турында хәбәр итмәгән очракта, ул 5 елга озайтылган дип санала.

## 5. КИЛЕШҮНЕҢ ГАМӘЛДӘ БУЛУ НИГЕЗЛӘРЕ ҺӘМ ТӘМАМЛАНУ ТӘРТИБЕ

5.1. Килешү, Яклар килешүендә башкасы каралган очраклардан тыш, гамәлдә булу вакыты узгач, туктатыла.

5.2. Әлеге Килешүнең гамәлдә булу вакыты вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

Яклар килешүе буенча.

- бер яклы тәртиптә түбәндәге очракта:

- Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарын һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнарын үзгәртү нәтиҗәсендә район Башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләрне үтәү мөмкин түгел дип табыла, йә килеп туган шартларда әлеге вәкаләтләр җирлек башкарма комитеты тарафыннан мөстәкыйль аеруча нәтиҗәле гамәлгә ашырылырга мөмкин булганда;

- Якларның берсенең әлеге Килешү нигезендә үз йөкләмәләрен үтәмәве яисә тиешенчә үтәмәве.

5.3. Әлеге килешүне өзү турында хәбәрнамә язма рәвештә җибәрелә. Килешү күрсәтелгән хәбәрнамәне җибәрү датасыннан 30 көн узгач өзелгән дип санала.

5.4. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, район Башкарма комитеты җирлек Башкарма комитетына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын кайтара.

## 6. ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

6.1. Яклар әлеге Килешүдә каралган бурычларны үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен Россия Федерациясе законнары һәм әлеге Килешү нигезендә җаваплы.

6.2. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык барлыкка килүгә нигез булырга мөмкин.

## 7. БӘХӘСЛӘРНЕ ЧИШҮ ТӘРТИБЕ

7.1. Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр Яклар тарафыннан сөйләшүләр уздыру һәм башка килештерү процедураларыннан файдалану юлы белән хәл ителә.

7.2. Бәхәсне сөйләшүләр уздыру һәм башка килештерү процедураларыннан файдалану юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнар нигезендә суд тәртибендә каралырга тиеш.

## 8. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

8.1. Әлеге Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара ризалыгы буенча кертелә һәм язма рәвештә өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

8.2. Әлеге килешү белән җайга салынмаган мәсьәләләр буенча яклар гамәлдәге законнарга таянып эш итәләр.

8.3. Тигез юридик көчкә ия булган әлеге Килешү - ике нөсхәдә, Якларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә төзелде.

## 9. ЯКЛАРНЫҢ ИМЗАЛАРЫ

| | |
|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе<br>_________________________ | Татарстан Республикасы<br>Ютазы муниципаль районы<br>Башкарма комитеты Җитәкчесе |
| ____________/_________________/ | ____________/_________________/ |
| М.У. | М.У. |